| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ХОЗЕСАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ХУЖА ХӘСӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

13 июль 2023ел Хуҗа Хәсән ав. №15

Кайбыч муниципаль районы «Хуҗа Хәсән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Хуҗа Хәсән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Хуҗа Хәсән авыл җирлеге советы тарафыннан расланган Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү өлешендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимен кабул итәргә.
2. Хуҗа Хәсән авыл җирлеге советына, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Кайбыч муниципаль районы бюджетыннан Хуҗа Хәсән авыл җирлеге бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында Кайбыч муниципаль районы Советы белән килешү төзергә.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башлыгы С.П.Матвеева